КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 май г.Казань № 452

Тархан җир асты минераль су чыганагы территориясен төбәк әһәмиятендәге дәвалау-савыктыру җирләре дип тану турында

Россия Федерациясе Җир кодексының XIX бүлеге, «Дәвалану өчен табигый байлыклар, дәвалау-савыктыру җирләре һәм курортлар турында» 1995 ел, 23 февраль, ФЗ-26 нчы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирләре һәм курортлар турында» 2015 ел, 5 июнь, 418 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының көньяк өлешендә, Олы Тархан авылы янында урнашкан Тархан җир асты минераль су чыганагы территориясен төбәк әһәмиятендәге дәвалау-савыктыру җирләре дип танырга.

2. Төбәк әһәмиятендәге «Тархан җир асты минераль су чыганагы» дәвалау-савыктыру җирлегенең тау-санитария саклык округы һәм ярдәмче зоналар чикләрен и аларның режимын (карарга теркәлә) расларга.

3. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетына түбәндәгеләр буенча чаралар үткәрүне тәкъдим итәргә:

төбәк әһәмиятендәге «Тархан җир асты минераль су чыганагы» дәвалау-савыктыру җирлегенең тау-санитария саклык округы чикләре, тау-санитария саклык округы чикләрендә территорияләрне хуҗалык максатында файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру;

территориаль комплекслы схемаларны, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир төзелеше схемаларын, районның планлаштыру проектларын һәм территорияләрне үстерүнең генераль планнарын эшләгәндә төбәк әһәмиятендәге «Тархан җир асты минераль су чыганагы» дәвалау-савыктыру җиренең тау-санитария саклык округы чикләрен исәпкә алуны оештыру.

4. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына төбәк әһәмиятендәге «Тархан җир асты минераль су чыганагы» дәвалау-савыктыру җиренең тау-санитария саклык округы чикләре һәм ярдәмче зоналары турында «Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына мәгълүматлар бирүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

5. «Волжские воды – К» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә төбәк әһәмиятендәге «Тархан җир асты минераль су чыганагы» дәвалау-савыктыру җирлеге өчен түбәндәгеләрне күздә тота торган оештыру-техник һәм башка чаралар планын эшләүне һәм үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

территорияне төзекләндерүне;

табигый дәвалау ресурсларын өстәмә өйрәнүне;

дәвалау-савыктыру җирлеген, шулай ук аның табигый дәвалау ресурсларын (факторларын) уңайлы экологик һәм санитария-эпидемиология торышында карап тотуны;

табигый дәвалау факторларын саклау, яшел үсентеләрне карау, ландшафт эшләрен һәм башка табигатьне саклау эшләрен үткәрүне;

юллар, су белән тәэмин итү системаларын, канализация төзү, энергия белән тәэмин итү, телерадиотапшыру һәм элемтәне.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин